*Бөек язучы, сәясәтче, көрәшче, тарихчы, җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйның тууына 140 ел тулу (1878–1954) һәм әдипнең 15 томлык әсәрләре басылып чыгу уңае белән язылды.*

# Кереш

2008 елда республика җәмәгатьчелеге олуг әдип, җәмәгать эшлеклесе, тарихчы галим һәм милли азатлык хәрәкәтенең күренекле идеологы Гаяз Исхакыйның (1878–1954) 130 еллык юбилеен билгеләп үтте. Шул уңайдан Татарстан Фәннәр академиясе югары уку йортлары һәм киң җәмәгатьчелек белән берлектә фәнни конференция уздырды. Моннан тыш, бөек әдипнең туган көненә багышланган истәлекле очрашулар, җыелышлар үткәрелде, концерт-спектакльләр куелды. Әдипнең якты истәлеген мәңгеләштерү максатында, аның дөнья буйлап сибелгән бай мәдәни мирасын барлау, өйрәнү, иҗатына багышланган фәнни хезмәтләр язу, юбилярның 15 томлык әсәрләр тупланмасын бастырып чыгару төгәлләнде.

1999 елның 30 июлендә туган җире Чистай районының Яуширмә авылында Г. Исхакыйның тарихи-этнографик музее ачылды. 1980 елларның икенче яртысына кадәр «буржуаз мөртәт», «куылган шәхес», «совет хакимияте һәм коммунистлар партиясенең явыз дошманы» саналып килгән Г. Исхакый һәм аның якты истәлеге, бай иҗат мирасы алдында баш июгә мөмкинлек фәкать совет системасы яшәүдән туктатылганнан соң гына туды. Шул нигездә әдипнең онытылган яисә каһәрләнгән әсәрләрен халкыбызга, мирасыбызга кайтару эше башланды.

Мәшһүр милләтпәрвәр, бөек әдипнең искиткеч бай, күпьяклы, эстетик нәзакәтле, тарихи-фәлсәфи ачышлар белән үрелгән сүнмәс иҗаты, кыйтгаларны урап, кабат халкына, туган туфрагына әйләнеп кайтты. Әйе, «...бәйсезлек өчен алып барган көрәшебездә без милләтнең барлык ватанпәрвәрләренең мирасын эшкә җигәргә тиешбез»[1].

[1] *Таһиров И.* Бәйсезлек баскычлары / Суверенлык турында уйланулар. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1994. – Б. 102.

Шунысын әйтергә кирәк: Г. Исхакыйның иҗатын гына түгел, исемен телгә алу да совет сәясәтчеләрендә ярсу һәм ачу тудырган бер чорда чит илләрдә, бигрәк тә Төркия белән Финляндиядә, бөек әдипнең күпкырлы эшчәнлеген һәм иҗатын өйрәнү эше үзе исән чагында да, вафатыннан соң да уңышлы дәвам итә.

Әдипнең мирасын барлау, өйрәнү һәм системага салу эше белән турыдан-туры Төркиядә күп еллар дәвамында милләтпәрвәр Мәхмүт Таһир шөгыльләнә. Аның бәрәкәтле эзләнүләре һәм сакчыллыгы ярдәмендә Г. Исхакыйның атаклы «Олуг Мөхәммәд» драмасы, үз Ватанына кайтып, укучыга иреште. Мәхмүт Таһир тарафыннан язылган «Милли көрәшче һәм милли әдәбиятчы Гаяз Исхакый» дигән монографик хезмәт әдипнең вафатына бер ел тулып килгән көннәрдә, 1955 елда, Төркиядә төрек телендә дөнья күрде. Г. Исхакый үзе дә 58 исемнән торган үз әсәрләре библиографиясен 1951 елда төрек телендә төзеп калдырган[1]. Әйе, Г. Исхакыйны тәнкыйтьләргә, кабул итмәскә мөмкин, әмма исемен һәм кылган эш-гамәлләрен искә алмый калу, күрмәмешкә салышу һич тә мөмкин түгел иде шул. Чөнки ул татар халкының XX гасырдагы иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни-рухи тормышында искиткеч зур роль уйнаган якты шәхес, илаһи таң йолдызы иде.

Тарихка Г. Исхакый, гаять үзенчәлекле, оригиналь прозаик, драматург булудан тыш, күренекле җәмәгать эшлеклесе, матбугат оештыручысы, ялкынлы публицист һәм большевизмны, аның милләтләрне үзбилгеләнүдән мәхрүм иткән сәясәтен урынлы һәм оста тәнкыйтьли белгән фикер иясе буларак кереп калды. Кыскасы, аның тормыш юлы һәм иҗаты тарихыбызның иң якты, матур һәм шул ук вакытта фаҗигале сәхифәсен тәшкил итә.

Шуңа күрә Г. Исхакыйның иҗтимагый-сәяси һәм тарихи карашларының формалашу процессы, аның күпьяклы һәм ялкынлы эшчәнлеге махсус өйрәнелүгә лаеклы. Татар тарихы һәм әдәбият фәне, җәмәгатьчелек аның якты истәлеге каршында һаман да бурычлы.

Бигрәк тә галим-әдипнең татар һәм башка милләтләрнең дәүләт төзелеш-корылышы кебек мөһим мәсьәләләрне хәл итүдә тоткан ролен, дөньяга карашын ачыклау – гаять кызыклы, бик вакытлы һәм урынлы, татар халкы яшәгәндә беркайчан да әһәмиятен югалтмый торган мәүзуг.

---

[1] Моңа охшаш башка публикацияләр дә булган, әлбәттә. Мәсәлән, М. Сәхапов хезмәтендә Г. Исхакый иҗатына багышланган һәм фәнни-теоретик, фәнни-методик характерда язылган 195 әдәби-фәнни чыганак китерелә. Бу хакта тулырак мәгълүматны М. Сәхаповның 1997 елда дөнья күргән «Г. Исхакый иҗаты» китабыннан табарга була (Б. 137–150).

Г. Исхакыйның күпкырлы эшчәнлегенең мәгънәсен һәм әһәмиятен конкрет тарихи бер дәвер – XIX гасыр азагы һәм XX йөз контекстында гына аңларга мөмкин, чөнки нәкъ шул чорда аның дөньяга карашының иҗтимагый йөзе һәм тирәлекне сәяси күрү сәләте калыплана. Нәкъ ул иҗатка килгән дәвердә татарның күренекле мәгърифәтчеләре, тарихчылары Шиһабетдин Мәрҗани (1818–1889), Хөсәен Фәезханов (1828–1866), Каюм Насыйри (1825–1902), Исмәгыйль Гаспралы (1851–1914), Рәшит Ибраһимов (1857–1944), Галимҗан Баруди (1857–1921), Риза Фәхретдинов (1859–1936), Габдулла Бубый (1871–1922), Муса Бигиев (1875–1949), Йосыф Акчура (1876–1935), Садри Максуди (1879–1935) һ. б. яңа чор – гасырның милли азатлык вә дини реформаторлык хәрәкәтен башлап җибәреп, уңышлы гына дәвам иттерәләр. Бу күренекле эшлеклеләрнең күпьяклы һәм каһарманнарча фидакяр эшчәнлеге нәтиҗәсендә татар халкы XX йөз башында, аеруча 1905 елгы инкыйлабтан соң, рухи-матди яшәешнең төрле тармакларында күтәрелеш чорын кичерә. Кызганычка каршы, демократик үсешнең тәүге үсентеләре 1917 елда, большевиклар илдә үз диктатураларын урнаштыргач юкка чыгарылдылар. Алдынгы эшлеклеләр һәм фикер ияләре аяусыз кырылды. Россия Федерациясе составында Идел-Урал Штаты да, гомумән, миллидәүләти статусын ала алмый калды.

1920 еллар уртасыннан ялтыравык шигарләр, купшы сүзвәгъдәләр чоры, демократия битлеге киеп, курчак уйнау дәвере үтү белән үк, Г. Баруди, Р. Фәхретдинов, Г. Бубый, Й. Акчура, С. Максуди, И. Алкин, Г. Шәрәф һ. б. күренекле прогрессив тарихчы, философ, җәмәгать эшлеклеләренең хезмәтләре катгый тыела башлады һәм юк ителде. 1985 елга кадәр Г. Исхакыйның гаять бай мирасы да халыкка җиткерелми килде.

Шул чордан башлап, язучы-прозаик, драматург буларак, Г. Исхакый иҗаты актив рәвештә өйрәнелә башлады. Әмма бер нәрсә бүген ачыклана һәм аныклана төште: Г. Исхакыйны никадәр генә «бөек әдип-язучы», «яңа реалистик прозага нигез салучы» дип атамыйк, бу аның гаять киң фикри диапазонын тулысынча иңли алмый. Күренекле хокук яклаучы, совет хакимияте өчен диссидент Али Акышның сүзләренә таянып, үзенең мәгълүм монографиясендә Миңнәхмәт Сәхапов бу хакта болай яза: «Җитмеш алты яшьлек гомеренең алтмыш елын Г. Исхакый милли азатлык хәрәкәтенә, илле биш елын матбугат эшенә багышлады. Ул «Ил», «Сүз», «Тавыш», «Ил сүзе», «Маяк», «Милли байрак», «Тәрәккый», «Таң», «Хөррият», «Таң йолдызы» газеталарын, «Милли байрак»ны оештыручы һәм чыгаручы булды... Аның әдәби, сәхнә әсәрләре һәм иҗтимагый-сәяси, һәм фәнни эчтәлекле

күпсанлы мәкаләләре, бүгенге көндә дә әһәмиятләрен югалтмыйча, милли әдәбиятыбызның алтын фондын тәшкил итәләр[1].

Йомгаклап шуны әйтергә кирәк: татар халкының бөек улы Г. Исхакыйның иҗат мирасын барлау һәм өйрәнүдә соңгы дәвердә күзгә күренеп торган җитди уңышларга ирешелде. Ике докторлык, биш кандидатлык диссертациясе яклanды. Әмма бөек әдипнең иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге, аның вакытлы матбугат үсешенә, тарих фәненә һәм тарихи чыганакларны өйрәнүгә керткән өлеше әле бүген дә фәнни әйләнешкә тулысынча кертелми калган «ак тап» булып кала бирә. Элеккерәк елларда тарихчы, язучы, журналист, җәмәгать эшлеклеләрен бер-берсеннән аерып, төрле жанрларны махсус өйрәнү кабул ителмәгән иде әле. Чор үзе халкыбызның сәләтле улларын тәрәккыяткә хезмәт итә торган күпьяклы, игелекле эшчәнлек алып баруга этәрде[2]. Мәсәлән, Газиз Гобәйдуллин (1887–1938), Казан университетының юридик факультетында бер ел укыганнан соң, тарихчы профессорлар М. М. Хвостов, Н. Н. Фирсов киңәшләренә колак салып, тарих-филология факультеты бүлегенә күчә һәм анда ныклап торып үз халкының тарихын, этногенезын өйрәнә башлый. Ш. Мәрҗани, Марко Поло иҗатлары буенча материаллар җыя, Ибн Халдун һәм Аристотель эшчәнлекләренә багышланган хезмәтләр язу белән беррәттән, «Г. Газиз» тәхәллүсе белән үзе дә юмористик һәм сатирик хикәяләр, рецензияләр бастырып чыгара.

Гаяз Исхакый да, нәкъ аның кебек, күпьяклы вә үзенчәлекле әдип буларак танылa. Аның мирасын өйрәнүгә Х. Миңнегулов, Ф. Галимуллин, И. Таһиров, Т. Галиуллин һ. б. галимнәребез зур өлеш керттеләр. Хикмәт аның ХХ йөз башындагы татар публицистларының иң сәләтле, иң көчлеләреннән, төбәктә иң актив җәмәгать эшлеклесе, эсерлар хәрәкәтенең танылган лидеры, большевиклар басымына каршы торырга сәләтле сәяси көрәшче булуында гына да түгел. Иң элек ул – «Идел-Урал» тарихи-фәлсәфи эссе авторы. Моннан тыш, аның байтак әсәрләре милләт тарихына багышланган яки тарихи-документаль нигезгә салынып иҗат ителгән. Болар барысы Г. Исхакый мирасын өр-яңадан системага салып, фәнни дәрәҗәгә күтәрүне һәм, гомумән, гыйльми өйрәнүне таләп итә. Г. Исхакый мирасын тикшерүчеләр игътибарыннан читтәрәк кала килгән өлешләрен дә фәнни әйләнешкә кертеп, тарихчы һәм философ, публицист һәм сәяси көрәшче буларак, тирәнрәк һәм күпьяклырак өйрәнү дәвере дә килеп җитте.

---

[1] *Сәхапов М.* Исхакый иҗаты : монография. – Казан : Мирас, 1997. – Б. 6.

[2] Шунда ук. – Б. 6.

Әлбәттә, әдипнең тормыш юлын һәм иҗат мирасын барлауда төп һәм нигезле чыганак – Г. Исхакыйның үз әсәрләре.

Басылып чыккан мәкаләләр һәм архив материалларын хронологик эзлеклелектә өйрәнү әдип һәм милли хәрәкәт теоретигы Г. Исхакыйның иҗади фикер сөреше үсешен тулырак күзалларга мөмкинлек бирде.

Әлеге хезмәтендә автор түбәндәге мәсьәләләрне калкытып куюны кирәк дип таба:

1) Г. Исхакыйның дөньяга карашы калыплашуда мәгърифәтчелек идеалларыннан эсерлар хәрәкәте программасы һәм күрсәтмәләренә таба барган үсеш юлын күзаллап чыгу;

2) аның Дәүләт Думасы депутатларына, «Иттифакъ» партиясе әгъзаларына һ. б. ның эшчәнлегенә булган мөнәсәбәтен фәнни дәлилләү;

3) XX гасыр милли хәрәкәт сәясәтен формалаштыруда Г. Исхакыйның ролен һәм урынын билгеләү;

4) милли азатлык хәрәкәте лидерларының берсе буларак, Г. Исхакыйның мөһаҗирлек чорында алып барган күпьяклы эшчәнлегенә тиешле бәя бирү.

Әдип үзенең атаклы «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрендә, Америка язучысы Белламиның «Йөз ел үткәч» романының утопик калыбын уңышлы һәм иҗади файдаланып, кайчандыр гөрләп чәчәк аткан милләтнең үз-үзен изоляцияләү, фикер сөреше тарлыгы, матди һәм рухи культураның түбән дәрәҗәдә торуы нәтиҗәсендә юкка чыга баруының коточкыч хәлен тасвир кыла. Чыгу юлын язучы тарихи үткәннәрдән иң уңай, прогрессив якларны куллануда һәм Европа, рус, Шәрык мәдәниятләре белән бердәмлектә күрә. Бу әсәрендә авторның җитлеккән аналитик гакылы, аяусыз реалистик вә тәнкыйди көче һәм ахыр чиктәге оптимизмы чагылыш таба. Бәянга язган кереш өлешендә автор «Ике йөз елдан соң инкыйраз»ның язылу максатын татар милләтенең хәзерге аң үсеш дәрәҗәсе илә риза булмавыннан, ә бу исә тулы бер халыкны юк ителүгә, һәлакәткә илтәчәген милләттәшләренә җиткерү иде дип белдерә. Үз халкының киләчәге өчен йөрәге әрнеп иҗат ителгән бу әсәр турында ул заманының әйдәп баручы язучы-әдипләре, галим һәм тарихчыларның күпчелеге уңай фикердә торганнар (Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Җ. Вәлиди, Г. Газиз һ. б.).

Мәсәлән, бу хакта Йосыф Акчура болай дип яза: «Элегрәк ул, үзалдына аерым индивидуумга чын күңелдән, романтикларча хезмәт итү бурычы куйган булса, тора-бара киң масса-гавамга, бигрәк тә ярлы һәм бөлгеннәргә ярдәм итү кирәклегенә төшенә бара, һәм аерым шәхескә булган мәхәббәт тулаем милләткә карата булган олуг мәхәббәткә кадәр үсеп җитә.